КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 18 февраль г.Казань № 98

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы вәзгыять турында мәгълүмат бирү тәртибен раслау хакында» 2021 ел, 16 апрель, 253 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы вәзгыять турында мәгълүмат бирү тәртибен раслау хакында» 2021 ел, 16 апрель, 253 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

татар текстында исемдә «вәзгыять» сүзеннән соң «, гражданнарның социаль-хезмәт хокуклары, эш белән тәэмин итү рәвешләрен үстерү» сүзләрен өстәргә;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясындагы 3 өлешенең 16 пункты һәм «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $^{21}$ статьясындагы 4 өлешенең 4 пунктындагы унҗиденче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

татар текстында 1 пунктта «вәзгыять» сүзеннән соң «, гражданнарның социаль-хезмәт хокуклары, эш белән тәэмин итү рәвешләрен үстерү» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында хезмәт базарындагы вәзгыять турында мәгълүмат бирү тәртибендә:

татар текстында исемдә «вәзгыять» сүзеннән соң «, гражданнарның социаль-хезмәт хокуклары, эш белән тәэмин итү рәвешләрен үстерү» сүзләрен өстәргә;

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасында гражданнарга һәм эш бирүчеләргә хезмәт базарындагы вәзгыять, гражданнарның социаль-хезмәт

хокуклары, Татарстан Республикасында эш белән тәэмин итү рәвешләрен үстерү турында мәгълүмат бирү буенча эш оештыруны регламентлаштыра (алга таба - мәгълүмат бирү).»;

1.2 пунктта «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт казна учреждениеләре (алга таба - халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре)» сүзләрен «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Мәгълүмат бирү хезмәт базарындагы вәзгыять, хезмәт базарында ихтыяҗ булган һөнәрләр (белгечлекләр) хакында, халыкның эш белән тәэмин ителеше өлкәсендә күрсәтелә торган дәүләт ярдәме чаралары турында, гражданнарның социаль-хезмәт хокуклары, эш белән тәэмин итү рәвешләрен үстерү турында, Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге башка гамәлгә ашырыла торган чаралар турында гражданнарга һәм эш бирүчеләргә актуаль мәгълүмат җиткерү максатларында гамәлгә ашырыла.»;

татар текстында II бүлек исемендә «вәзгыять» сүзеннән соң «, гражданнарның социаль-хезмәт хокуклары, эш белән тәэмин итү рәвешләрен үстерү» сүзләрен өстәргә;

2.1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.1. Хезмәт базарындагы вәзгыять, гражданнарның социаль-хезмәт хокуклары, Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү рәвешләрен үстерү турындагы мәгълүмат Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (алга таба - Министрлыкның рәсми сайты) (http://mtsz.tatar.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенең социаль челтәрләрдә әлеге Тәртипнең 2.3 пункты нигезендә исемлек буенча аена кимендә бер тапкыр урнаштырыла.»;

2.2 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Гражданнарга һәм эш бирүчеләргә хезмәт базарындагы вәзгыять, гражданнарның социаль-хезмәт хокуклары, Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү рәвешләрен үстерү турындагы мәгълүматны җиткерү максатларында мәгълүмат бирүнең 2.1 пунктында күрсәтелгән ысулына өстәмә рәвештә хәбәр ителә:»;

өченче абзацта «халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең» сүзләрен «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенең» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Хезмәт базарындагы вәзгыять, гражданнарның социаль-хезмәт хокуклары, Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү рәвешләрен үстерү турында мәгълүмат түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала:

эшче көчләр, эш белән тәэмин ителүчеләр һәм эшсезләр саны (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча);

эшче көчләрдә, эш белән тәэмин итүдә һәм эшсезлектә катнашу дәрәҗәләре (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча);

«Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесендә теркәлгән эшсезләр саны;

теркәлә торган эшсезлек дәрәҗәсе;

хезмәт базарындагы киеренкелек коэффициенты;

эш бирүчеләр тарафыннан «Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә белдерелгән буш эш урыннары һәм вакантлы вазыйфалар саны, шул исәптән дистанцион (ерактан торып) эшләү буенча;

хезмәткәрләрнең социаль-хезмәт хокуклары;

Татарстан Республикасында яшәү минимумы һәм минималь куллану бюджеты зурлыгы ;

Россия Федерациясендә хезмәт өчен түләүнең минималь күләме;

Татарстан Республикасында минималь хезмәт хакы;

хезмәт базары үзенчәлекләрен характерлаучы башка мәгълүмат һәм аналитик материаллар.»;

2.4 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2.5 пунктта «хезмәт» сүзеннән соң «, гражданнарның социаль-хезмәт хокуклары, эш белән тәэмин итү рәвешләрен үстерү» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин